Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

**2021 елның 13 декабре** **№ 75**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 декабрендәге 107 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Су кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы Уставының 7, 99, 100, 101 статьялары нигезендә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү белән , Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2007 елның 27 июнендәге 107 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**13 статьяның 2 пунктындагы 3 пунктчасына түбәндәге сүзләр өстәргә:**

«3) әйләнә-тирә мохиткә, мәдәни мирас объектларына зыян китерү».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы урынбасары Г.Ә.Габидуллинга йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы**
**муниципаль районы Башлыгы,**
**муниципаль район Советы рәисе** **Н.А.Вазыйхов**